ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

28.04.2026 г. Казань № 43-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 29 гыйнварындагы 10-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе карамагындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 29 гыйнварындагы 10-од номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2026 елның 2 февралендәге 10-од номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4.1 пунктта:

1 пунктчада «өч» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктчада «өч» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

4.1 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Хокук бүлеге җитәкчесенә Р.Ф.Шәяхмәтовка әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары И.Т.Гыйниятуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе башлыгы Т.М. Галиев